

Кабыгы белән пешкән яшь бәрәнгене, костёрда пешереп, пешә-пешә ашау ни тора. Кvпләр ул бәхетле мизгелне кичергән инде, тик бәрәнге Мордовия халыкынын бер ук вакытта олгерми икән, унышы да торлечә була. Торле районнарда бәрәнге унышы ничек?

Дубенка районы Ломат авылыннан Мәзидә Муракаева гаиләсе әлегә vткән елгы иске бәрәнгеләрен ашыйлар.

13 майда бәрәнгене чәчтек, ди Мәзидә Якуб кызы.- Торле сортларны утыртабыз: Голландия (кызыл, алсу, сап-сары, аграк тостәге) бәрәнгеләре дә бар бездә. Башта янгырлар юк иде, жир катты, vсә алмады бәрәнгебез, соныннан янгыр яугач, vсә башлады инде. Казып караган идем, бvгенгә бәрәнгебез вак; вакыт бар – vсәр әле. Быел безнен якларда барыбызнын да шулай. Корбан гаете коннәренен берсендә Ләмберәдән кунаклар килгән иде, аларда да шул ук хәл дип әйттеләр.

Бәрәнге  элек-электән кешене ачлыктан коткарган. Хәзер дә авыл халкы нәрсәгә тотынса да, ин беренче бә- рәнгене куллана. Безнен кvп кенә милли ризыклар да бәрәнгегә кайтып кала. Бәйрәм ашларынын кvбесендә бәрәнге кулланып пешердем. Очпочмагы дисен-ме, мантые һәм башка милли ризыкларда ул бар, - ди Мәзидә Муракаева.

Бәрәнгенен унышы быел соендерәме дигән соравыма Атюрьево районы Большой Шуструйда гомер итvче Эльвира Совешова сойләде.

- Барлыгы 7-8 сотый жирдә бәрәнге vстерәбез. Жарлар иде, быел бәрәнгегә нык кvп корт тоште, яфракларын ашаган, ике тапкыр агуладым. Кайберәvләрнен бәрәнгесен корт ашап та бетерде диярлек; совсем калмады, аларнын бәрәнгесеннән уныш та котәргә юк.Ә без бер-ике атна яна бәрәнгене ашыйбыз инде; ел әйләнәсенә vзебезгә житәрлек булыр дип уйлыйм. Ералманын эресе 7-8 булса, вaклары кvп. Үсәрә вакыт бераз бар, унышны омет белән котәбез.

Рузаевка районы Татар Пешләсе авылында яшәvче Голчәчәк Чурбанова янгырлар яумый торгач, бәрәнге булмый дип нык борчылган идек - яуды, ди. Быел уныш бар яшелчәдән дә булып килә, бәрәнгебез дә булыр дип уйлый ул.

- Без иртә олгерә торган бәрәнгене бер ай элек ашый башладык. Сон олгерә торганын алып караган юк әле. Быел бәрәнге бик әйбәт. Иртә олгерә торганы бер топтән 11-14 бәрәнге чыга. Янгырлар яуды, файдасы булыр. Бәрәнге vсәр очен бераз вакыт та бар әле.

Бәрәнге орлыгын vзебезнекен калдырабыз, сортларын белеп бетермим инде. Бәрәнгене кызыл тостәге агу белән агулап утыртабыз, шуна корт тими. Иртә олгерә торганын алай агуламадык, шуна кайбер топләренә агуны соныннан сиптереп чыгарга кирәк булды. Агулап чәчvнен зыяны кvптер, сvз дә юк, тик ул бик унайлы.

Мундирда пешергән яшь бәрәнге - ин тәмлесе. Бик яратып ашыйм. Яна кишер, кәбестә, кабачок, бәрәнге белән казанда яшелчә ашы ясадык, ул да бик тәмле булды. Французча бәрәнгене бик яратып ашыйбыз. Анын рецепты бик жайлы. Саламлап тураган бәрәнгене майлаган табага тезәм, анын остенә тоз, борыч сибәм. Икенче катка фарш жәям, анын остенә кыздырылган суган белән кишер, аннан майонез сылыйм, остенә сыр уам һәм духовкага тыгып куям. Мин бәрәнгенен теләсә ничек пешерелгәнен дә яратам. Ә балаларнын алай исе китми, - диде Голчәчәк Чурбанова.
Торбеево районы Тат.-Юнки авылында да бәрәнге унышына омет бар. Нәфисә Абдрахман кызы Салихметова әле бәрәнге vсәр очен бер ай вакытыбыз алда, ди.
- Ералма (бәрәнге) унышы безнен якларда яхшы булырга ошый. Беренче бәрәнгене алып ашадык, бик тәмле. Бер топтән каз йомыркасыннан зуррак булган биш-тугыз бәрәнге, кайбер топләреннән кечкенәсен дә кvпләп алабыз. Сортыннан да килә ул. Тагы чәчv вакыты да зур роль уйный - иртә чәчкәннәрнен зурлар булып vскәннәр. Киленебезнен бәрәнгесе бик эре, бик яхшы, чонки бик ундырылышлы сортлысын иртә чәчкән. Корт тошмичә генә дә булмады, авылыбызда бәрәнгеләрен ике-оч тапкыр да агулаучылар булды, мин vзем урыны-урыны белән булганнарын гына ятладым. Бәрәнге бакчабызда корт кvп булмады быел. Безнен якта быел жил дә вакытында исте, янгыр да вакытында яуды, Аллага шокер. Икенче икмәкнен унышы белән мин канәгать, әле vсәргә вакыты бар. Ел да vзебезгә житәрлек була.

**Наилә НАСЫРОВА**